ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮҖӘКӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423734, Күҗәкә авылы,
Совет ур.,28 нче йорт.
Тел/факс 3-44-48

СОВЕТ КУЗЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423734, село Кузякино,
ул. Советская, дом 28.
Тел/факс 3-44-48

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 января 2020 года №2

**Актаныш муниципаль районының Күҗәкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге Советы карары “07” сентябрь 2017 ел № 21 белән расланган**

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Күҗәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге Советына таянып

**карар бирә**:

1. Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13.1 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а)сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу, яллаучы вәкиленең Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) муниципаль берәмлек муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешма идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә күрсәтү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

2.1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

1.2. 25.3 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- "25.3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында«Куҗәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе
Куҗәкә авыл җирлеге рәисе Мусин И.Н.